КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 сентябрь г.Казань № 956

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карары белән расланган «Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында приз алучыларны һәм җиңүчеләрне әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм күрсәтү» гранты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1078 нче; 2022 ел, 29 июнь, 613 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында приз алучыларны һәм җиңүчеләрне әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм күрсәтү» гранты турындагы нигезләмәгә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Грантның күләме (G) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$G = V \times N,$$

монда:

V – грантның Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына әзерләнгән приз алучылардан һәм җиңүчеләрдән чыгып билгеләнә торган, ай саен түбәндәге күләмнәрдә бирелә торган түләү күләме:

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер приз алучыны әзерләүчегә – 10,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына ике приз алучыны әзерләүчегә – 15,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына өч приз алучыны әзерләүчегә – 20,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына дүрт приз алучыны әзерләүчегә – 25,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына биш приз алучыны әзерләүчегә – 30,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер җиңүчене әзерләүчегә – 10,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына ике җиңүчене әзерләүчегә – 15,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына алты приз алучыны әзерләүчегә – 35,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында максималь күләмдә балл җыйган бер абсолют җиңүчене әзерләүчегә – 20,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер җиңүчене һәм бер приз алучыны әзерләүчегә – 15,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер җиңүчене һәм ике приз алучыны әзерләүчегә – 20,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер җиңүчене һәм өч приз алучыны әзерләүчегә – 25,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына ике җиңүчене һәм бер приз алучыны әзерләүчегә – 20,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына ике җиңүчене һәм ике приз алучыны әзерләүчегә – 25,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына ике җиңүчене һәм өч приз алучыны әзерләүчегә – 30,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына өч җиңүчене һәм өч приз алучыны әзерләүчегә – 35,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер абсолют җиңүчене һәм бер приз алучыны әзерләүчегә – 30,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер абсолют җиңүчене, бер җиңүчене һәм бер приз алучыны әзерләүчегә – 40,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер абсолют җиңүчене, ике җиңүчене һәм ике приз алучыны әзерләүчегә – 45,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер абсолют җиңүчене, өч җиңүчене һәм ике приз алучыны әзерләүчегә – 50,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына бер абсолют җиңүчене, ике җиңүчене һәм 10 приз алучыны әзерләүчегә – 60,0 мең сум;

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабына ике абсолют җиңүчене һәм бер җиңүчене әзерләүчегә – 50,0 мең сум;

N – 12 айга тигез булган грант түләү срогы.

Грант аны алучыга агымдагы финанс елында ай саен грант алучының кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына грант күләме чикләрендә һәм грант бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тигез өлешкә бүлеп түләнә.

Грантларның иң чик саны бер елга иң күбе 150 грант тәшкил итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин